# Караш

…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№7 2013. Март
«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге

## МӘКТӘПТӘ... шундый эшләр

**Дума тарафыннан оетырылган төрле акцияләр дәвам ителә. Бигрәк тә “Икелеләрсез атна”, “Ветеран янәшәдә” акцияләрендә эш актив бара. Мәктәптә оештырылган һәр чарада дума әгъзалары төп көчне тәшкил итәләр.**

**11 нче сыйныфлар өчен урак өсте. Аларны сынай формасында оештырылган Бердәм Дәүләт Имтиханнары көтә. Беренче кат бирелгән сынау имтиханнарында сынатучылар булмады. Бу атнада икенче кат сынау алдында калучы унберләргә уңыш телибез.**



МББУ “Лашман гомум белем бирү мәктәбе” башлангыч һәм уртасыйныф укучылары авылыбызның «Ләйсән" балалар бакчасында бик матур итеп әзерләнгән концерт күрсәттеләр. Галия Динмөхәммәтова җитәкчелегендәге «Ләззәт" һәм "Шатлык нуры" төркеме кызлары моңлы тавышлы җырлары белән, Гүзәл Шакирова җитәкчелегендәге "Энҗе бөртекләре" һәм "Дуслык" хореографик төркеме укучыларының дәртле биюләре, декоратив гамәли бүлегендә шөгыльләнүче укучыларының иҗат җимешләреннән оештырылган күргәзмә - нәни дусларыбызның һәм аларның тәрбиячеләренең күңелләренә хуш килде. Концерт ахырында нәни дуслар кушылып бии дә башладылар.

*БУ АЙДА... Казанда Идел буе Федераль Спрот һәм туризм академиясе кубогына йөзү ярышлары булды. Безнең команда җиңүчеләр исәбендә. Йөзүчеләребезгә әлеге спорт төре буенча профессиональ шөгыльләнүчеләр беләр рәттән ярышырга туры килде. Алар сынатмадылар!*

*БУ АЙДА... фән олимпиадаларының республика туры тәмамланды. Анда катнашып район данын яклаган укучыларга рәхмәтебезне җиткерәбез.*

*БУ АЙДА... “Ягез әле, кызлар!” бәйгесе узды. Башка еллардан аермалы буларак, ул бик эчтәлекле итеп оештырылган иде. Кичә барышында “Иң тапкыр”, “Иң сөйкемле”, “Иң уңган” һ.б шундый номинацияләр буенча җиңүче кызларыбыз билгеләнде. Афәрин, кызлар!*

*БУ АЙДА... район үзешчәннәренең смотр-концертына сайлап алу турлары булып узды. Гала-концерт этабына үткән биюче кызларыбызны (“үзбәк кызлары биюе”) котлыйбыз!*

*БУ АЙДА... 5-7 нче сыйныфлар арасында ветеран укытучы Ахтәм Фатыхов кубогына “Быстрее, выше, сильнее” эстафетасы уздырылды. 7 нчеләр – беренче!*

*БУ АЙДА... район газетасы кубогына шахмат уены буенча ярышлар булып узды. 11 нче сыйныфтан Айсинә Әскарова – 2 нче урын иясе!*

*БУ АЙДА... өченче озын чирек бетә һәм каникул!!!!*

# Әдәби почмак

## “БЕЗ – ТУКАЙ ВАРИСЛАРЫ!”
## конкурсына тәкъдим ителгән эшләр

**Елак кыз.**

“Нигә елап утырасың,
Иртә таңнан?” – ди әби
“Киен, кызым, зинһар, эшкә
Соңга калам !” – ди әни.
“Елатмагыз, баланы”,- дип
Бабай йөри янымда.
“Чәеңне дә эчмәгәнсең,
Суына ич табында”
“Синең кебек матур кызлар
Утырмый иртән елап.”
“Чәрелдәмә! Тавышыңны
Кара син үзең тыңлап.”
Көн дә елап алам шулай
Барысын да биетеп.
Озаталар “Ярый әле
Бакчасы бар!” – диешеп..



**Әбүнәгыймова Аделина 5 нче сыйныф.**

**Иң кадерлем - әнием"**

Син әнием, минем өчен
Бу дөньяда бер генә.
Син-минем иң якын кешем,
Яратам сине гомергә.
Иң кадерле, иң хөрмәтле
Булсын жирдә әниләр!
Әниләрне хөрмәтләсәк,
Тыныч булыр ил-көннәр.

**Заляков Ильнур. 7 нче сыйныф.**

**Китап**

Яктылыкка юл күрсәтер,
Начарлык тәкъдим итмәс.
«Тәртипсезлек сукмагында
Йөрмә, - дияр, - кирәкмәс!»
Кирәк булса булышыр ул,
Авыр хәлдән чыгарыр.
Аптыраган кешегә
Ярдәм кулын ул сузар.
Белем диңгезендә йөзә
Китап белән һәр бала.
Син дә дустым калышма,
Китаплар укып кара.

**Газимжанова Гөлинә 7 нче сыйныф**



**Яратам мәктәбемне!**

Мина берсе сорау бирде.
Бик сәер сорау иде.
“Нигә син яратасан
Мәктәбегезне?” - диде.
Озак уйлап тормадым мин,
Шундый жавап кайтардым:
Ничек инде мәктәбемне
Яратмаска булдырыйм?
Өйрәтә бит ул безне
Укырга һәм язарга.
Монда өйрәндем әле мин
Балык кебек йөзәргә.
Чыңлы кынгыравы белән
Каршы ала һәр иртә.
Алда кирәк булыр эшнең
Һәммәсенә өйрәтә.
Анда укый минем гаиләм
Минем гаиләм-дусларым.
Уйнап- көлешеп йөрибез
Һәрбер тәнәфес саен.
Минем хисләрем белән
Тулы нәни йөрәгем.
Яратмаска мөмкин түгел –
Ул бит минем мәктәбем!

**Гатина Фәйрүзә 7 нче сыйныф.**











**Минем сеңлем.**

Сеңелем минем кечкенә,
Аңа бит бер яшь кенә!
Үзе шаян, үзе наян.
Булыша бар эштә дә.
Уйнап-көлеп шаяра ул,
Кайвакыт елап ала.
Барыбер яратам аны
Яратмыйча буламы?

**Срурдинова Ләйлә 7 нче сыйныф**

“Караш” газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Газимзянова Р. Ф.
Хәбәрләшү өчен телефон: 9270444015

# Рәхмәтебез чиксез сезгә!



Укытучы апам... Беренче сыйныфтан дүртенче сыйныфка кадәр, шатлыкларны гына түгел, борчуларны да уртаклашып, акыллы киңәшләрен биреп, безне укырга, язарга, бик күп белем серләренә өйрәткән беренче укытучым – Кадрия апа Динмөхәммәтованы күпләр беләдер. Ул инде күп еллар мәктәбебездә хезмәт куя. Кадрия апа минем әниемнең дә беренче укытучысы булган. Үземнең беренче тапкыр курка-курка сыйныфка кергәнемне хәтерлим әле. Мөлаем елмаеп, тавышы белән үк күңелләргә тынычлык иңдереп, инде күптән мине белгән кебек яратып, аркамнан сөеп каршы алган иде ул. Шул көннән алып, безне урта сыйныфларга озатып калганчы икенче әниебез кебек булды Кадрия апа. Сыйныфыбызда 16 бөртек баланың һәркайсының күңеленә юл таба, кызыксындыра белде. Туган телебездә дөрес сөйләшергә, олыларны олыларга, кечеләрне хөрмәт итәргә өйрәтте укытучыбыз. Ул һәрвакыт безнең белән иде. Нинди генә бәйрәм кичәләр оештырмый иде ул. Табигать кочагына, музейларга ясаган экскурсияләр вакытында күпме яңалык, белем бирде ул. Тынгысыз, кабатланмас, иҗади, эзләнүчән... 2007 нче елда "Ел сыйныф җитәкчесе" бәйгесендә районда 1 нче урынны алып зона ярышларында уңышлы чыгыш ясавы, быел исә "Ел укытучысы" бәйгесендә икенче урын алуы аның шундый шәхес булуын кабат дәлилли түгелме? Үз максатына ирешүче Кадрия апабыз безне дә нәкъ шулай тәрбияләде. Без инде быел тугызынчы сыйныфта укыйбыз. Алда җитди имтиханнар. Моңа кадәр әле беребез дә беренче укытучыбызның йөзенә кызыллык китермәде – ныклы әзерлек белән килгәзнебез сизелеп торды. Алда да уңышлар көтсен иде! Безнең һәр уңышыбызда СЕЗнең дә өлешегез бар, Кадрия апа! Сезгә дә киләчәктә зур уңышлар, нык исәнлек, сабырлык телибез!

**Газимҗанова Рания 9 нчы сыйныф укучысы**

***Укытучыма...***

*Еллар үткән саен сезнең исем,*
*Якыная бара күңелгә.*
*Ирешә алган һәр уңышым өчен*
*Мин рәхмәтле СЕЗГӘ бу көндә.*
*Елаганда елмаерлык юаттыгыз.*
*Егылганда тотып калдыгыз.*
*"Минекеләр" диеп укыттыгыз,*
*Бәхет теләп озатып калдыгыз.*
*Нинди генә сүзләр табыйм соң*
*Рәхмәтемне сезгә әйтергә?*
*Иң яхшысы – безнең турында*
*Гел матур сүз язсын ишетергә!*

Свою первую учительницу я полюбила сразу. Её имя - Кадрия Равгатовна, в переводе оно обозначает « уважаемая, дорогая». Она такая красивая, добродушная, ласковая.

Первый класс - самый трудный класс. Я не любила рисовать, потому что не умела. Урок рисования - самый легкий, интересный урок. Это я сейчас так думаю. А тогда каждый новый урок рисования сопровождался слезами. Только Кадрия Равгатовна терпеливо, с урока на урок, вместе со мной рисовала. И ведь пришел успех --- я научилась! Это была не только моей победой, она была нашей с учителем! Я должна научиться быть терпеливой - это самое нужное качество для учителя. В наших успехах есть заслуга и первой учительницы. Каждый из моих одноклассников смогли выделиться чем-то среди других. Есть у нас лауреаты «Созвездия», победители различных конкурсов. Я была очень счастлива, когда заняла первое место по району на игре «Русский медвежонок », а Кадрия Равгатовна гордилась мной. Умение радоваться за успехи других - это важное качество для учителя. Все учителя заслуживают уважения и похвалы, а особенно моя первая учительница. Я такая счастливая, потому что каждое утро мы с нашими девчонками проходим мимо кабинета Кадрии Равгатовны. Встреча с ней обещает нам удачный день. Её улыбка, похвала, милое лицо придают нам силы жить и учиться на отлично. Нынче у неё первоклашки. Как я им завидую! Сколько нового, увлекательного ждёт их вместе с учителем. В течение короткого времени я для себя открыла удивительную профессию учителя. Да, я хочу многое перенять у своей учительницы. Это, как мне кажется, неплохо. Ведь всегда легче идти по натоптанной тропе. А путеводной звездой для меня станет моя первая учительница.



**Шакирзянова Алина Ученица 9 класса**

# БЕРЕНЧЕЛӘР БЕРЕНЧЕ КАТ КАЛӘМ СЫНЫЙ

**Минем гаиләм.**



Минем гаиләм зур һәм тату. Гаиләдә без барысы алты кеше яшибез. Әтием, әнием, апам, энем, әбием һәм мин үзем. Әтием белән әнием мәктәптә укытучы булып эшлиләр. Апам унберенче сыйныфта укый. Әбием лаеклы ялда, ул өйдә тора. Үзем беренче сыйныфта укыйм. Мәктәп миңа бик ошый. Мин укырга теләп барам. Ә энем әле кечкенә, шуңа күрә әнием әле эшләми, ул энемне үстерә. Әбием дә аңа булыша. Мин энемне бик яратам, мәктәптән кайтканчы ук аны сагынам. Ул кулларын миңа сузып, матур итеп елмая. Әнием без мәктәптән кайткан җиргә тәмле ашларын пешереп көтеп ала. Аннан без бергәләшеп зур өстәл артына җыелабыз. Рәхәт тә соң, шундый матур, зур, тату гаиләң булу!!!

**Мөбаракшина Алия 1 нче сыйныф укучысы**



**Минем якын дустым.**

Минем туган көнемә әтием песи баласы алып кайтты. Әтием белә инде ул минем песиләрне ничек яратканымны. Ул үзе дә песиләр, этләр, атлар ярата. Шулай итеп, минем якын дустым – яраткан тере уенчыгым булды. Ул шундый матур, йомшак, ап-ак тун кигән. Исеме – Актәпи, чөнки аның тәпиләре ап-ак. Ул уйнарга бик ярата. Без аның белән качышлы уйныйбыз. Мин качсам, шунда ук таба. Ә мин аны эзли-эзли арып бетәм. Аннары ул үзе килеп чыга, берни булмагандай иркәләнә башлый. Без икәү бергә йоклыйбыз. Ә иртән ул мине мәктәпкә озата. Мин ашыгам, ул миннән дә катырак ашыга. Ә кайтканымны тәрәзә төбендә көтеп утыра. Ул да мине ярата!

**Талипова Эльвина 1 нче сыйныф укучысы**

**Минем гаиләм.**

Безнең гаиләдә биш кеше – Әти, Әни, Алия апам, Илнур абыем һәм мин. Әтием нефтяник булып эшли. Абыем Илнур Казан шәһәрендә югары уку йортында укый. Алия апам 11 нче сынйныфта белем ала. Ә мин 1 нче сыйныфта укыйм. Без бик тату гаилә.

**Закирова Дилә 1 нче сыйныф укучысы**

Хөрмәтле укучылар! Беренче коймак төерле була дисәләр дә, беренче сыйныф укучыларының иҗатларын күргәч, минем моңа инануым какшады әле. Күрдегезме, нинди оста алмаш үсә? Әнә Алия “Бозда куркынычсызлыкны тәэмин ит!” бәйгесендә РЕСПУБЛИКА күләмендә җиңеп чыкты. Тантаналы төстә планшет тапшырганда дәү-дәү апаларының, абыйларының күзендә ак көнләшү ярылып ята иде бит. “Минем гаиләм” бәйгесендә дә уңышлы чыгыш ясадылар башлангычлар. Димәк, булдыралар. Афәрин! Алдагы саннарыбызга да башлангыч сыйныфлардан язмалар көтеп калабыз. “Без - Тукай варислары” бәйгесе дә дәвам итә. Уңышны кулдан ычкындырмагыз!